**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6154**
**07.11.2022**

Башкарма комитетның «2021 елның 10 октябрендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында булган авиация катастрофасында һәлак булганнарның туганнарын, якыннарын, шулай ук L-410 самолеты һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүгә җәлеп ителгән затларны тукландыруны, яшәтүне, транспорт белән тәэмин итүне оештыру буенча хезмәт күрсәткән юридик затларның һәм (яки) шәхси эшмәкәрләрнең чыгымнарын кире кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү турында» 2022 елның 21 октябрендәге 5701 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системсы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2021 елның 10 октябрендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында булган авиация катастрофасында һәлак булганнарның туганнарын, якыннарын, шулай ук L-410 самолеты һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүгә җәлеп ителгән затларны тукландыруны, яшәтүне, транспорт белән тәэмин итүне оештыру буенча хезмәт күрсәткән юридик затларның һәм (яки) шәхси эшмәкәрләрнең чыгымнарын кире кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү турында» 2022 елның 21 октябрендәге 5701 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2021 елның 10 октябрендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында булган авиация катастрофасында һәлак булганнарның туганнарын, якыннарын, шулай ук L-410 самолеты һәлакәте нәтиҗәләрен

бетерүгә җәлеп ителгән затларны тукландыруны, яшәтүне, транспорт белән тәэмин итүне оештыру буенча хезмәт күрсәткән юридик затларның һәм (яки) шәхси эшмәкәрләрнең чыгымнарын кире кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 53 пунктында «шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе» сүзләрен «икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2021 елның 10 октябрендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында булган авиация катастрофасында һәлак булганнарның туганнарын, якыннарын, шулай ук L-410 самолеты һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүгә җәлеп ителгән затларны тукландыруны, яшәтүне, транспорт белән тәэмин итүне оештыру буенча хезмәт күрсәткән юридик затларның һәм (яки) шәхси эшмәкәрләрнең чыгымнарын кире кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү буенча комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- комиссия составыннан чыгарырга:

И.Н. Гайнуллинны;

Р.М. Мингалиевны;

- комиссия составына кертергә:

Кропотова Наталия Анатольевнаны – комиссия әгъзасы, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары;

Сәгъдиев Айрат Сәгыйть улын – комиссия секретаре, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы урынбасары, эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү бүлеге башлыгы.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев